РЕШЕНИЕ КАРАР

27 .06. 2016 №12-4

**Тәтеш муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның үз-үзләрен тотышына булган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Комиссия турындагы нигезләмәне раслау хакында**

2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында " 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. 1 нче кушымта) Тәтеш муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның үз-үзләрен тотышына карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында Нигезләмәне раслау (№1 нче кушымта).

2. Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның үз-үзләрен тотышына карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия составын раслау (2 нче кушымта).

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Советының 12.11.2014 ел, №51-6, 04.04.2016 ел, №11-6 карарларын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Тәтеш муниципаль районы Советының Җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә (И.и. Хисамова).

Татарстан Республикасы

Тәтеш муниципаль районы

Башлыгы Р.Х. Сафиуллов